Р.Р.Сәлахова
Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты (г.Казань)

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ОМОМОРФЕМАЛАР

Татар теле белемендә сүзнең морфологик төзелеше, морфемаларның функциональ төрләре турындагы теория, вакыт сынавын үтеп, шактый төзек система булуын күрсәтте. Сөйләмдә бер үк мәгънәдә кулланыла һәм фонетик составы бер-берсенә якын булган морфларның, тел яссылыгында алганда, морфема дигән гомуми төшенчәгә тупланулары билгеле. Бер морфема төзү өчен бер үк мәгънәгә ия булган морфлар аваз составлары буенча да охшаш булырга тиешләр. Мәсәлән, сөйләмдә төрле сүзформаларда кулланыла торган ***–дан/-дән, -тан/-тән, -нан/-нән*** морфлары тел яссылыгында бер морфемага кереп бетәләр. Тел белүченең аңында да болар бер морфема буларак истә калалар, фонетик яктан гына ассимиляциягә биреләләр. Шулай итеп, төрле сүзформада кулланылган бер исемдәге, бер мәгънәдәге һәм бер-берсенә якын яңгырашлы морфлар берләшмәсе морфема дип атала [6: 162].

Фонетик яктан охшашлык булмаса, берүк мәгънә белдерсәләр дә, морфлар бер морфема төземиләр, төрле морфемаларга керәләр. Мәсәлән, *капты**рма**, капты**ргыч*** сүзформаларында ***–ма, -гыч*** морфлары мәгънәләре ягыннан бер үк, ләкин авазларда охшашлык юк. Шуңа күрә алар икесе ике төрле морфема буларак каралалар [5: 78].

Төрле мәгънәле бер үк аваз төзелешенә ия булган морфлар да аерым морфемалар төзиләр. Мондый морфемаларны омоним морфемалар яки омоморфемалар дип атыйлар [4, 67]. Татар телендә әлеге төшенчәгә беренчеләрдән булып игътибар бирүче тел белгече Х.Курбатов омоморфемаларны грамматик омонимнарның бер төре итеп карый. “Омоморфема – телнең морфологик төзелешендә. Аваз составы бер үк, ләкин грамматик мәгънәсе бөтенләй башка булган ясагыч яки төрләндергеч кушымчалар омоморфемалар булалар”, - дип яза галим [3: 87-88]. Әмма омоморфема төшенчәсенә төрле мәгънәгә ия булган һәм төрле функция үти торган аваздаш кушымчалар яки синтаксик конструкцияләрне (омомодель) генә түгел, ә тамыр морфемаларны да кертеп карау мөһим. Чөнки морфлар кебек үк, морфема да тамыр һәм кушымча төрләргә бүленәләр. Омонимлык күренеше тамыр морфемалар арасында да, кушымча морфемалар арасында да, шулай ук тамыр һәм кушымча морфемалар арасында да күзәтелә.

Татар телендә омоморфемаларның түбәндәге төрләрен аерып чыгарырга мөмкин: 1.**Тамыр морфема ~ тамыр морфема**:

а) лексик, ягъни бер үк сүз төркеменә карый торган тамыр омоморфемалар:

Төш I – кайбер үсемлекләрнең җимешләрендә каты кабыклы орлык. *Өстәлдә **төш**ләре алынып ташланган чикләвек кабыклары ята(Ф.Ә.).*

Төш II – урын мәгънәсендә. *Һәрбер җылы тунлы кешеләрнең җылы бүрке, торыр **төш**е бар(Һ.Т.).*

ә) лексик – грамматик, ягъни төрле сүз төркеменә караган тамыр омоморфемалар:

Без I – беренче зат күплек формасындагы зат алмашлыгы. ***Без*** *безгә без дибез, Сез безгә ни дисез? (табышмак).*

БезII – күн, киез, такта һ.б.ш. әйберләрне кечкенә диаметрлы итеп тишеп чыгара торган эш коралы. ***Без*** *капчыкта ятмый (мәкаль).*

Без III – чыңлаудан түбәнрәк дулкынлы озын авазны белдерә. ***Без-без, без****еелди, “Борынымда бар безем”, - ди (табышмак).*

2. **Кушымча морфема ~ кушымча морфема:** а)лексик, ягъни яңа лексик мәгънә ясый торган сүз ясагыч кушымча омомофемалар:

***-гы/-кы***I – исем ясагыч: *чал**гы,** ярал**гы,** той**гы,** чап**кы,** оет**кы.** Шулай да Фәтхидәге уңайсызлану **тойгысы** озакка сузылмады» (Ш.К.).*

***-гы/-кы***II – сыйфат ясагыч: *яз**гы**, кыш**кы.** Көзге ашлыкны көлгә чәч, яз**гы** ашлыкны бозга чәч (мәкаль).*

***-гы/-кы***III **–** фигыль ясагыч: *туз**гы,** пыс**кы**. Зур ялкыннар гына җылы биә, пыс**кы**п янган утта мәгънә юк (Ә.Е.)* [4: 77-80].

ә) грамматик, ягъни сүзнең грамматик мәгънәсен үзгәртә торган форма ясагыч һәм бәйләгеч(төр һәм төрләндергеч) кушымча омоморфемалар:

***-ар/-әр***I – киләчәк заман сыйфат фигыль кушымчасы: *куй**-ар** урын,* ‘место, куда следует класть*’, гөлләр үс**әр** көн, оч**ар** кош. Өч баламны оч**ар** кош итеп, Мин очырдым иркен далага (М.Җ).*

***-ар/-әр***II – бүлем саны кушымчасы: *ун**ар,** тугыз**ар,** бер**әр**, өч**әр**. Агач, агач саен ботак, ботак саен оя, оя саен күкәй – сигез**әр** дә тугыз**ар** (табышмак).* [4:135-136].

б) лексик-грамматик, ягъни сүз ясагыч һәм граматик (форма ясагыч һәм бәйләгеч) кушымча омоморфемалар:

***-са/-сә***I – исем ясагыч кушымча: *муен**са**, җиң**сә**, култык**са.** Зәңгәр җиң**сә**ләр кигән почта кызларының пресслы печатьне шапылдатып конверт өстенә сугулары ишетелә (Г.А.).*

***-са/-сә***II – шарт фигыль кушымчасы: *кычкыр**са**, кил**сә**. Торна кычкыр**са,** көн җылыныр. Аккош иртә кил**сә**, яз начар булыр(мәкаль)* [4: 150-151].

3. **Тамыр морфема ~ кушымча морфема**: а) лексик – лексик:

АйI – күк җисеме. *Бик сагынсаң **ай**га кара, мин карыйм йолдызларга (җыр).*

АйII – астрономик елның уникедән бер өлеше. *Казаннан кайтканга хәзер биш **ай** бардыр инде ( Г.К).*

***-ай***III – фигыль ясагыч кушымча: *начар**ай**, матур**ай,** аз**ай**, карт**ай**. Карт**ай**ган икән әнисе, аның да килен рәхәтен күреп яшисе киләдер (Г.Б* ).

***-ай***IV – сыйфат ясагыч кушымча: *уң**ай**, кул**ай**.* «*Бу юри шулай кыланадыр, сугып егар өчен бер уң**ай** әйбер эзлидер, я булмаса кычыткан янына алып бара торгандыр», – дигән уй йөрәгемне өзлексез талап торды (М.Ә.).*

ә) лексик – лексик-грамматик:

КырI – урмансыз тигезлек, зур тигез ачык мәйдан. *Тулган ай үзенең моңсу нурларын урманнар, **кыр**лар өстенә чәчеп әкрен генә йөзә(Г.Ә.).*

КырII – нәрсәнең дә булса чите, кырые, тирәсе. *Аның башында киң **кыр**лы эшләпә, өстендә җиңел сары плащ, аягында күн итек иде(Г.Ә.).*

***-кыр***III – сыйфат ясагыч кушымча: *тап**кыр**. Мин үзем дә җавапка бик тап**кыр** кеше, бер дә аптырап тормадым (Ф.Х.).*

***-кыр***IV – фигыльләрдә йөкләтү юнәлеше кушымчасы: *ят**кыр**. – Авыру кешегә җылы булыр дип, мич башына ят**кыр**ган идек без аны (М.Г.).*

б) <u>лексик-грамматик – лексик</u>:

КерI – юылган яки юылырга тиешле өс-баш киемнәре һәм тукымадан тегелгән төрле көнкүреш кирәк-яраклары. *Миңсылу **кер** тукмаклый (Һ.Т.).*

Кер(ү)II – берәр нәрсәнең эченә таба хәрәкәт итү, кая да булса үтү, берәр нәрсәнең чиген үтү. *Беренче малай урылмаган җир өстенә **кер**еп китте(И.Г.).*

***-кер***III – сыйфат ясагыч: *үт**кер**. Атым ярсыган, кылычым үт**кер**, Син, ярсу атым, Әйдә, утка кер(Ф.К.).*

***-кер***IV – фигыль ясагыч: *ү**кер.** Ике үгез үкерә-үкерә Күккә менә, Җиргә сикерә(Н.И.).*

Мисаллардан күренгәнчә, татар телендә омонимик мөнәсәбәтләр, нигездә, тамыр һәм кушымча (суффикс) арасында күзәтелә. Бу телнең агглютинативлыгы белән аңлатыла. Аффиксаль морфеманың башка төрләре (префикс, инфикс) булган телләрдә омоморфемаларның түбәндәге төрләрен очратырга мөмкин: **префикс-префикс**: ***пере**весить* (картину) – ***пере**весить* (получить перевес) [2: 9-10]; **префикс-суффикс**: ***ent** –**ent**sprechen- Stud**ent***;

**суффикс-суффикс:** ***-ed*** ***–*** *ring “кольцо” - ring**ed** “с кольцом” – to work “работа” - work**ed** “работал”* [1: 56].

***-ин*** *– хворост – хворост**ин**а, изюм – изюм**ин**а, глубокий – глуб**ин**а - глуб**ин**ы, великий – велич**ин**а –велич**ин**ы* [2: 8].

Омоморфемаларны билгеләгәндә, телнең морфонологик үзенчәлекләрен исәпкә алу бик мөһим, чөнки морфемалар чигендә күзәтелгән төрле аваз үзгәрешләре омонимик мөнәсәбәтләр тууга сәбәп була алалар. Телдәге мондый мөнәсәбәтләрне тикшерү морфонология, морфология, синтаксис, сүзъясалышы кебек тел белеменең шактый катлаулы тармаклары белән бәйле күп кенә үзенчәлекләрен билгеләргә мөмкинлек бирә.

Файдаланылган әдәбият

1. Броун В.В. Некоторые вопросы омонимии: Автореф. дис. ... канд. филол. наук.– Тбилиси, 1958.– 22 с.

2. Виноградов В.В. О грамматической омонимии в современном русском языке // Рус. яз. в школе.– 1940.– №1.– С.1–12.

3. Курбатов Х.Р. Грамматические омонимы в татарском языке // Татар теле һәм әдәбияты.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1959.– С.307-311.

4. Салахова Р.Р. Омонимичные суффиксы татарского языка. Казань: Gumanitarya, 2007. -204 с.

5. Татарский язык: Проблемы и исследования / Сост.: Ф.А.Ганиев.– Казань, 2000.– 432 с.

6. Татар грамматикасы: Өч томда. – Т.1. – Мәскәү: Инсан, Казан: Фикер, 1998. – 642 б.